**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 12 август № 587

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 елда, Россия Федерациясе Пенсия фонды субсидиясен җәлеп итеп, Татарстан Республикасында яшәүче эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә укытуны оештыру турында» 2015 ел, 30 июнь, 471 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 елда, Россия Федерациясе Пенсия фонды субсидиясен җәлеп итеп, Татарстан Республикасында яшәүче эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә укытуны оештыру турында» 2015 ел, 30 июнь, 471 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының халыкка социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләренең матди-техник нигезләрен ныгыту һәм картлык буенча һәм инвалидлык буенча хезмәт пенсияләре алучы эшләмәүче пенсионерларга адреслы социаль ярдәм күрсәтү һәм эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә укыту белән бәйле социаль программаларын финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында» 2011 ел, 10 июнь, 456 нчы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 23 декабрь, 1023 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм» дәүләт программасын тормышка ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

күрсәтелгән карар белән расланган 2015 елда, Россия Федерациясе Пенсия фонды субсидиясен җәлеп итеп, Татарстан Республикасында яшәүче эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә укытуны оештыру тәртибенең 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әлеге 2015 елда, Россия Федерациясе Пенсия фонды субсидиясен җәлеп итеп, Татарстан Республикасында яшәүче эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә укытуны оештыру тәртибе (алга таба – Тәртип) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының халыкка социаль хезмәт

күрсәтү учреждениеләренең матди-техник нигезләрен ныгыту һәм картлык буенча һәм инвалидлык буенча хезмәт пенсияләре алучы эшләмәүче пенсионерларга адреслы социаль ярдәм күрсәтү һәм эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә укыту белән бәйле социаль программаларын финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында» 2011 ел, 10 июнь, 456 нчы карары һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 23 декабрь, 1023 нче карары нигезендә өлкән яшьтәге затларның дәүләт мәгълүмат ресурсларыннан файдалана алуын тәэмин итү максатларында эшләнгән һәм 2015 елда, Россия Федерациясе Пенсия фонды субсидиясен җәлеп итеп, Татарстан Республикасында яшәүче эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә укытуны оештыру тәртибен билгели.»;

күрсәтелгән карар белән расланган 2015 елда Татарстан Республикасында яшәүче эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә укыту белән бәйле Татарстан Республикасы социаль программасын тормышка ашырганда барлыкка килгән Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанслашуга Татарстан Республикасы бюджетына Россия Федерациясе Пенсия фонды бюджетыннан субсидияне тоту тәртибенең 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әлеге 2015 елда Татарстан Республикасында яшәүче эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә укыту белән бәйле Татарстан Республикасы социаль программасын тормышка ашырганда барлыкка килгән Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанслашуга Татарстан Республикасы бюджетына Россия Федерациясе Пенсия фонды бюджетыннан субсидияне тоту тәртибе (алга таба – Тәртип) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының халыкка социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләренең матди-техник нигезләрен ныгыту һәм картлык буенча һәм инвалидлык буенча хезмәт пенсияләре алучы эшләмәүче пенсионерларга адреслы социаль ярдәм күрсәтү һәм эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә укыту белән бәйле социаль программаларын финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында» 2011 ел, 10 июнь, 456 нчы карары һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 23 декабрь, 1023 нче карары нигезендә Россия Федерациясе Пенсия фонды һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасын нәтиҗәле һәм максатлы файдалану максатларында эшләнгән һәм 2015 елда, Россия Федерациясе Пенсия фонды субсидиясен җәлеп итеп, Татарстан Республикасында яшәүче эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә укыту белән бәйле Татарстан Республикасының социаль программасын тормышка ашырганда барлыкка килгән Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанслашуга Россия Федерациясе Пенсия фонды бюджетыннан Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләрне (алга таба – Субсидия) тоту тәртибен билгели.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры — И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\587.docx